КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 646

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турында

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү эшен камилләштерү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турындагы нигезләмәне (алга таба – «Алгарыш» гранты турындагы нигезләмә);

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәне;

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча республика комиссиясе составын.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын (алга таба – «Алгарыш» гранты) бирүне оештыру өчен җаваплы һәм «Алгарыш» грантын бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган грант бирүче итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ел саен, 1 августка кадәр, «Алгарыш» гранты турындагы нигезләмәгә таянып, киләсе елга өстенлекле белгечлекләр исемлеген Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кертергә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «Алгарыш» грантын финанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетында, бюджетның керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, әмма ел саен кимендә 100,0 млн.сум (шуларның 10 проценты «Югары белем бирүче мәгариф оешмалары» категориясе буенча «Алгарыш» грантын финанслауга җибәрелә) күләмендә чыгымнар күздә тотарга.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына грант алучы, грант алу датасы, грант алучы укыган категория, уку урыны турында белешмәләре булган мәгълүматлар базасын алып барырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 26 июль, 646 нчы
карары белән расланды

Россия һәм чит ил мәгариф һәм фәнни оешмаларында гражданнарны әзерләүгә һәм аларның стажировкасына «Алгарыш» Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча республика комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Республика комиссиясе рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Республика комиссиясе рәисе урынбасары |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, Республика комиссиясенең җаваплы секретаре |

«Яшь белгечләр», «Укытучылар һәм фәнни хезмәткәрләр», «Югары белем бирүче мәгариф оешмалары» категорияләре буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия

| | |
|---|---|
| Гафуров Илшат Рәфкать улы | Татарстан Республикасының Югары уку йортлары ректорлары советы рәисе, югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улы | югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Алибаев Тимур Лазович | югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Алишев Тимирхан Булат улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең тышкы элемтәләр буенча проректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызы | югары белем бирүче «Казан дәүләт мәдәният һзм сәнгать институты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем һәм фән бүлеге башлыгы |
| Калачев Алексей Алексеевич | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фән учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Созинов Алексей Станиславович | Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының югары белем бирүче «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Солтанова Дилбәр Шамил кызы | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреж-дениесенең уку-укыту эшләре буенча проректоры (килешү буенча) |
| Хәсәнов Рөстәм Шамил улы | Казан дәүләт медицина академиясе – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирүче «Россия медицина өзлексез һөнәри белем бирү академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреж-дениесе филиалы директоры (килешү буенча) |

«Яшь галимнәр», «Ике диплом» категорияләре буенча
грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча
ярдәмче комиссия

| | |
|---|---|
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе |
| Абдуллин Айрат Лесталевич | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты (килешү буенча) |
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улы | югары белем бирүче «Казан дәүләт энергетика универ-ситеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Алибаев Тимур Лазович | югары белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Кареева Юлия Рөстәм кызы | Татарстан Республикасы яшь галимнәре һәм белгечләренең төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе, WorldSkills хәрәкәтенең сертификацияләнгән эксперты |
| Копылов Александр Юрьевич | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең фәнни эшләр буенча проректоры (килешү буенча) |
| Минзарипов Рияз Гатаулла улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең беренче проректоры (килешү буенча) |
| Низамов Рәшит Корбангали улы | югары белем бирүче «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Хәсәнов Рөстәм Шамил улы | Казан дәүләт медицина академиясе – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирүче «Россия медицина өзлексез һөнәри белем бирү академиясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалы директоры (килешү буенча) |

«Мәгариф оешмалары хезмәткәрләре» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия

| | |
|---|---|
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе |
| Гафиятуллин Нияз Мансур улы | «Казанның халыкара мәктәбе» коммерциягә карамаган автоном гомуми белем бирү оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Җәләлева Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нугуманова Людмила Николаевна | өстәмә һөнәри белем бирүче «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Прохоров Юрий Петрович | Халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Ризванов Ирек Асаф улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Юнусов Булат Марсель улы | «Белем бирү сыйфатын мониторинглауның республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |

«Проект төркемнәре» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия

| | |
|---|---|
| Шакиров Динар Рәфикъ улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе |
| Абдуллин Айрат Лесталевич | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты (килешү буенча) |
| Агиев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Глазков Андрей Александрович | «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең персонал белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Лаврентьев Александр Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм эшмәкәрләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Савва Арсен Владимирович | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Фёдоров Андрей Александрович | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының корпоратив идарә бүлеге башлыгы |

«WorldSkills» категориясе буенча грант алырга теләүчеләр арасыннан грант алуга сайлап алуны үткәрү буенча ярдәмче комиссия

| | |
|---|---|
| Җәләлева Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры, Республика комиссиясе рәисе урынбасары, ярдәмче комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улы | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Кареева Юлия Рөстәм кызы | Татарстан Республикасы яшь галимнәре һәм белгечләренең төбәк яшьләр иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе, WorldSkills хәрәкәтенең сертификацияләнгән эксперты |
| Проснев Александр Владимирович | «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Рамазанова Дамира Әкъмәл кызы | «Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының фәнни-җитештерү һәм инновация эшчәнлеге буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Савченко Разия Фатыйх кызы | «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Фаретдинов Айдар Рафис улы | «Н.В.Лемаев исемендәге Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча). |